СОВЕТ ЕЛАБУЖСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АЛАБУГА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ КАРАР

22.10.2019 Алабуга шәһәре № 410

**Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Советы депутатларының ачык утырышларында гражданнарның (физик затларның) катнашуын тәэмин итү тәртибен раслау турында**

2009 нчы елның 9 февралендә чыккан 8 санлы «Дәүләт органнары һәм җирле үзидарә органнары эшчәнлеге турындагы мәгълүматка үтемлелекне тәэмин итү турында» Федераль закон, 2003 елның 6 октябрендәге 131 санлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 35 маддәсе, Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Советы

КАРАР кабул итте:

1. Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Советы депутатларының ачык утырышларында гражданнарның (физик затларның) катнашуын тәэмин итү тәртибен расларга.
2. Әлеге карар рәсми басылып чыгарга тиеш.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны муниципаль төзелеш, хокук тәртибе һәм депутат этикасы мәсьәләләре буенча даими депутат комиссиясенә йөкләргә.

Рәис урынбасары З.Х.Сөнгәтуллина